# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Апаз авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**“16” ноябрь 2023 ел** **№ 5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 16 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«2024 елда Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Апаз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- Гагарин, Базар, Совхоз урамнарында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю;
- Гагарин урамының 26 йортыннан 30 йортына кадәр юл-урам челтәрен вак таш белән каплау;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Апаз авылында су челтәрләрен ремонтлау;
- авылны төзекләндерү җиһазлары өчен запас частьләр сатып алу (бензин чапкычы, бензин пычкысы);
- “Сабантуй” милли бәйрәмен үткәрү урынын төзекләндерү (материаллар алу);
- МТЗ 82 тракторына прицеплы җиһазлар сатып алуны финанслау (үзбушаткыч тагылма)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 354 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 188 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 188 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Апаз торак пунктында халык җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «2024 елда Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Апаз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- Гагарин, Базар, Совхоз урамнарында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю;
- Гагарин урамының 26 йортыннан 30 йортына кадәр юл-урам челтәрен вак таш белән каплау;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Апаз авылында су челтәрләрен ремонтлау;
- авылны төзекләндерү җиһазлары өчен запас частьләр сатып алу (бензин чапкычы, бензин пычкысы);
- “Сабантуй” милли бәйрәмен үткәрү урынын төзекләндерү (материаллар алу);
- МТЗ 82 тракторына прицеплы җиһазлар сатып алуны финанслау (үзбушаткыч тагылма)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә, ТР, Арча районы, Апаз авылы, Совет урамы, 19 йорт адресы буенча мәгълүмат стендларында, Арча муниципаль районының (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов